СОВЕТ
РОМОДАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
РОМОДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с. Ромодан **КАРАР**

22.07.2026 г № 22

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге Советының 14.08.2023 ел, № 42 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Ромодан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертүне раслау турында**

Идел буе транспорт Прокуратурасының 03.06.2026 ел, №23/1-2-2026 протестын үтәү йөзеннән, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел № 33-ФЗ Федераль законның 16 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге Советының 14.08.2023 ел, № 42 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Ромодан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/),Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Ромодан авыл җирлеге Башлыгы,**
**Совет рәисе** **И.А. Чекалина**

СОВЕТ РОМОДАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге Советының авыл җирлеге Советының 22.07.2026 № 22 карарына кушымта

**Ромодан авыл җирлеге Советы карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге Советының 14.08.2023 ел, № 42 карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Ромодан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

1) 38 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктында «һәм тимер юл транспортының контакт челтәрен» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 56 статьяның 1 өлешендә «тимер юл транспортының контакт челтәре таянычлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 56 статьяның 4 өлешендә «һәм тимер юл транспортының контакт челтәре таянычларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 79 статьяның 4 өлешендәге 4 пунктында «4) торак массивлар, җәмәгать урыннары һәм социаль объектлар территориясендә хуҗалары булмаган хайваннарны ашату. Искәрмә – тыю җирле үзидарә органы тарафыннан хуҗасыз хайваннарны ашату өчен махсус оештырылган урыннарга кагылмый» сүзләрен төшереп калдырырга.

**Ромодан авыл җирлеге Башлыгы,**
**Совет рәисе** **И.А. Чекалина**

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ РОМОДАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЕ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ТАТАРСТАН
СОВЕТ РОМОДАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ